# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 2 09.12.2019 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баек авыл җирлеге составына керүче Дусай торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Дусай торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Дусай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә, көндезге формада укучы студентларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 350 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Дусай авылы юлларын ремонтлау һәм карап тоту.
- Дусай авылында Сабантуй бәйрәмнәрен үткәрү урыннарын төзекләндерү, электр белән тәэмин итү җайланмасы алу, бүләкләр сатып алу.
- Дусай авылында массакүләм чаралар үткәрү өчен бүләкләр сатып алу (Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май, 23 февраль; 8 Март; юбилярларны котлау, спорт ярышлары уздыру өчен чыгымнар, ритуаль хезмәтләргә чыгымнар).
- Дусай авылына урам яктырткычлары сатып алу.
- Дусай авылы территориясендә үлән чабу һәм куаклар кисү.
- Дусай авылында аз керемле гаиләдәге балаларга ярдәм итү.
- Дусай авылы мәдәният йортын ремонтлау.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Баек авылы, Совет урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Баек авыл җирлеге башлыгы** **Ф.М.Фахерлегаянов**